Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №Х-6**

Балык Бистәсе штп. 2021 елның 28 июне

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгының Мактау грамотасы турында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Рәхмәт хаты хакында

Гражданнарның Балык Бистәсе муниципаль районы алдындагы зур казанышларын тану, аларның районны үстерүгә юнәлдерелгән шәхси эшчәнлекләрен кызыксындыру, хезмәтне стимуллаштыру һәм иҗтимагый тормыштагы активлыкларын хуплап бүләкләү максатларында, Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 30 маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бүләкләрен гамәлгә куярга:

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгының Мактау грамотасын;
- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Рәхмәт хатын.

2. Кушымта итеп бирелә торган түбәндәгеләрне расларга:

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгының Мактау грамотасы турында Нигезләмәне;
- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Рәхмәт хаты турында Нигезләмәне.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2014 елның 13 декабрендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгының Мактау грамотасы турында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Рәхмәт хаты хакында”гы XLII -7 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы Аппараты җитәкчесе Җамалиев Р. Р. ка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык  Бистәсе муниципаль районы
Башлыгы  урынбасары                                        Ф.Г. Әхмәтҗанова

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының 2021
елның 28 июнендәге
Х-6 номерлы карары белән
расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгының Мактау грамотасы турында Нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгының Мактау грамотасы (алга таба – Мактау грамотасы) гражданнарны һәм предприятие һәм оешмаларның хезмәт коллективларын районның иминлеген-муллыгын тәэмин итүгә һәм халыкның тормыш-көнкүрешен яхшыртуга юнәлдерелгән эшчәнлек, югары һөнәри осталык һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен бүләкләү формасы булып тора.

1.2. Мактау грамотасы белән бүләкләү гражданнарның, предприятие һәм оешмаларның хезмәт коллективларының җирле үзидарәне, икътисад, җитештерү, социаль өлкәне, мәдәният, тәрбия һәм мәгарифне, сәламәтлек һәм әйләнә-тирә мохитне саклауны, законлылык, хокук тәртибен һәм иҗтимагый иминлекне, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының үсешен, абруен һәм дәрәҗәсен күтәрүгә ярдәм итә торган башка эшчәнлекне үстерү буенча иҗтимагый һәм муниципаль эшчәнлек өлкәсендә зур казанышларын тану билгесе итеп башкарыла.

1.3. Мактау грамотасы белән бүләкләнә:

а) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан, милек рәвешләренә һәм кайсы ведомствога каравына карамастан, предприятиеләрнең һәм оешмаларның хезмәт коллективлары;

б) Россия Федерациясе гражданнары.

1.4. Бүләкләү турында карар район Башлыгы карары белән төзелгән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының дәүләт һәм ведомство бүләкләре, муниципаль бүләкләре белән кызыксындыру һәм бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау буенча комиссия тәкъдиме буенча (алга таба – Комиссия) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгы (алга таба - район Башлыгы) тарафыннан кабул ителә һәм карар белән рәсмиләштерелә. Бүләкләү турында район Башлыгы карары гаммәви мәгълүмат чараларында рәсми рәвештә басылып чыгарга яисә Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

1.5. Мактау грамотасы белән бүләкләү кызыксындыруга тәкъдимнамәләр кергән саен гамәлгә ашырыла. Бүләкләү бәйрәмнәргә, истәлекле көннәргә, юбилей

даталарына туры килергә мөмкин. Юбилей датасы дигәндә әлеге Нигезләмәдә аңлашыла:

- оешмаларның хезмәт коллективлары өчен – 10 ел һәм алга таба оешма төзелгән мизгелдән алып һәр 5 ел саен;

- гражданнар өчен – 50 яшькә җитү һәм аннан соң һәр 5 ел саен туган көн.

1.6. Мактау грамотасы белән бүләкләүгә бәйле чараларны матди-техник һәм оештыру ягыннан тәэмин итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлеге (алга таба – оештыру бүлеге) гамәлгә ашыра.

1.7. Мактау грамоталарын исәпкә алу оештыру бүлеге тарафыннан алып барыла.

## II. Мактау грамотасы белән бүләкләүгә тәкъдим итү тәртибе

2.1. Мактау грамотасы белән бүләкләү турындагы мәсьәләне карау өчен кызыксындыруга лаек хезмәт коллективының яисә гражданның конкрет казанышларын күрсәтеп бүләкләүгә тәкъдимнамә кертелә.

2.2. Гражданнарны һәм хезмәт коллективын бүләкләүгә тәкъдим итүне милек рәвешләренә бәйсез рәвештә предприятие һәм оешмалар коллективлары, иҗтимагый оешмалар, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнары кертә.

2.3. Бүләкләү инициаторы район Башлыгы исеменә бүләкләүгә тәкъдимнамә кертә. Бүләкләүгә тәкъдимнамә бүләкләү күздә тотылган көнгә кадәр 15 календарь көннән дә соңга калмыйча әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасына ярашлы рәвеш буенча кертелә.

2.4. Мактау грамотасы белән бүләкләүгә тәкъдимнамәгә түбәндәге документлар теркәлә:

- хезмәт коллективлары өчен – социаль-икътисадый, фәнни һәм башка казанышлар турында мәгълүматлар; юбилей датасы уңаеннан бүләкләнгәндә – оешманың барлыкка килү датасы турында белешмә; салымнар буенча бурыч булмау турында белешмә;

- гражданнар өчен – салымнар буенча бурыч булмау турында белешмә (яисә мәгълүмат); 2 нче кушымтага ярашлы рәвештә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык.

2.5. Бүләкләү документлары район Башлыгы тарафыннан комиссиягә алар килеп ирешкән көннән соң өч көн эчендә җибәрелә.

2.6. Комиссия алар кергән көннән алып җиде көн эчендә тәкъдим ителгән документларны карый һәм район Башлыгына бәяләмә кәгазе белән карар җибәрә.

Бәяләү кәгазенең рәвеше район Башлыгы карары белән тәгаенләнә.

Уңай хәл ителгән очракта оештыру бүлеге район Башлыгының карар проектын әзерли һәм Мактау грамотасын рәсмиләштерә. Кире кагылган очракта Комиссия дәлилләнгән карарны рәсмиләштерә, аңа законда билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

2.7. Мактау грамотасы район Башлыгы яки ул булмаганда район Башлыгы урынбасары, район Башлыгы вазыйфаларын башкаручы тарафыннан имзалана һәм герблы мөһер белән таныклана.

2.8. Әлеге грамота белән бүләкләнгән гражданнар, предприятие һәм учреждениеләрнең хезмәт коллективлары Мактау грамотасы белән бүләкләнүгә алдагы бүләкләүдән соң 5 елдан соң кабат тәкъдим ителә алалар.

## III. Мактау грамотасын тапшыру тәртибе

3.1. Мактау грамотасы тантаналы шартларда район Башлыгы тарафыннан шәхсән яки аның кушуы буенча һәм аның исеменнән башка вазыйфаи затлар тарафыннан тапшырыла.

3.2. Мактау грамотасын тапшыру район Башлыгының бүләкләү турында карары чыккан көннән бер айдан да соңга калмыйча башкарылырга тиеш.

3.3. Бүләкләнүче үлгән очракта исән чакта тапшырылмаган Мактау грамотасы саклау өчен аның гаиләсенә бирелә.

3.4. Мактау грамотасы белән бүләкләнгән затлар аның сакланышына сак карарга тиешле. Мактау грамотасы югалган очракта дубликаты бирелми.

## IV. Мактау грамотасының тасвирламасы

4.1. Икеләтелгән А3 альбом форматындагы Мактау грамотасы битнең ике ягында да тулы төсле басма методы белән башкарылган.

4.2. Грамотаның тышкы өлеше – ак төстә, рамканың өске өлешенә бизәк төшерелгән. Үзәктә район гербы сурәтләнгән, рус һәм татар телләрендә исеме язылган.

4.3. Үзәк буенча уртадан бөкләнү ике А4 форматында.

4.4. Эчке өлеше рамка белән уратып алынган, өстә үзәктә район флагы сурәтләнгән.

4.5.Мактау грамотасына кертелә: бүләкләнүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм вазыйфасы, казанышлары исемлеге, район Башлыгы (аның вазыйфаларын башкаручы затның) имзасы (Грамотаның сул ягында – татар телендәге текст, уң ягында – рус телендәге текст урнаштырыла).

**Татарстан Республикасы**
**Балык Бистәсе муниципаль районы**
**Башлыгының**
**Мактау грамотасы турындагы**
**Нигезләмәгә кушымта №1**

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгының
Мактау грамотасы
белән бүләкләүгә

ТӘКЪДИМНАМӘ

Ф.И.А.и. (оешманың аталышы)____________________________________________

______________________________________________________________________

Туган елы, ае, числосы (төзелү датасы) ____________________________________

______________________________________________________________________

Белеме, уку йортының исеме (аталышы), тәмамлау елы

______________________________________________________________________

Эш урыны һәм вазыйфасы ________________________________________

Гомуми эш стажы ______________________________________________________

Тармактагы эш стажы ___________________________________________________

Әлеге предприятиедәге эш стажы _________________________________________

Дәүләт бүләкләре ______________________________________________________

Кызыксындыруларның, бүләкләүләрнең башка

төрләре___________________________________________

Наличие (отсутствие) судимости __________________________________________

Наличие (отсутствие) дисциплинарного взыскания___________________________

Конкрет казанышларын күрсәтеп бүләкләүгә тәкъдим ителүчегә сыйфатнамә

Кызыксындыруның инициаторы:

Җитәкче (җирле үзидарә,
оешма, предприятие, иҗтимагый оешма органы) _______________
(имза)

М.У. 20___ елның ____ ___________

**Татарстан Республикасы**
**Балык Бистәсе муниципаль районы**
**Башлыгының**
**Мактау грамотасы турындагы**
**Нигезләмәгә кушымта №2**

# ШӘХСИ МӘГЪЛҮМАТЛАРНЫ ЭШКӘРТҮГӘ РИЗАЛЫК

**Мин**, _______________________________________________________________________,

(ФИАи тулысынча)

___________________________________________________адресы буенча теркәлгән,

_________________________________________________________________________________,

шәхесне таныклаучы документ: _____________, серия: _____ номер: ______________

бирү датасы «_____» __________________, кем тарафыннан бирелгән

______________________________

_________________________________________________________________________________

"Шәхси мәгълүматлар турында"гы 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 маддәсе нигезендә

**үземнең эш бирүчемә** ________________________________________

_________________________________________________________________________________

(эш бирүче оешмасының аталышы)

минем шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә **ризалыгымны бирәм**, аерым алганда, эш бирүчегә тәкъдим ителгән тормышымның фактлары, вакыйгалары һәм шартлары турында мәгълүматлар белән "Шәхси мәгълүматлар турында" 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 3 маддәсендә каралган гамәлләрне кылуга.

"Шәхси мәгълүматлар турында" 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә аларны эшкәртүгә ризалыгымны биргән минем шәхси мәгълүматларымны, шул исәптән:

паспорт мәгълүматлары, белем турындагы мәгълүматлар (уку йортының исеме, аны тәмамлау елы, белгечлек), җенес, бүләкләр турындагы мәгълүматлар (шул исәптән бүләкләү датасы), кызыксындыруның башка төрләре булу турындагы мәгълүматлар, эш стажы турындагы мәгълүматларны

"Шәхси мәгълүматлар турында" 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 6 маддәсе нигезендә мине Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләүгә тәкъдим итү, Татарстан Республикасы дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары исеменнән кызыксындыруга тәкъдим итү максатларында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары исеменнән кызыксындырылган затлар турында "Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында" 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә мәгълүмат саклау максатларында **һәркем (өчен мөмкин) файдалана алырлык дип санауны сорыйм.**

**Мин килешәм**

минем шәхси мәгълүматларымны эшкәртү 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы "Шәхси мәгълүматлар турында" Федераль закон таләпләренә тулысынча туры китереп башкарылу белән.

**Минем шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгым һәм әлеге килешүдә (ризалыкта) күрсәтелгән максатлар өчен һәркем файдалана ала торган буларак аларны куллану** минем язма рәвештә ясаячак аерым күрсәтмәмә кадәр вакыты чикләнмәгән булып тора.

_____________________ (тутыру датасы)

_____________________ (мөрәҗәгать итүченең имзасы)

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2021 елның 28 июнендәге X-6 номерлы карары белән расланды**

## Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Рәхмәт хаты турында Нигезләмә

### I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Рәхмәт хаты (алга таба – Рәхмәт хаты) икътисадны, сәнәгать, фән, мәдәният, сәнгать, мәгариф, сәламәтлек саклау, спорт, җирле үзидарәне үстерүгә аеруча шәхси өлеш керткән өчен, законлылыкны, хокук тәртибен тәэмин итү, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен яклау эшендәге казанышлары, район һәм аның халкы алдындагы бүтән казанышлары (ирешкән уңышлары) өчен кызыксындыру формасы булып тора.

1.2. Рәхмәт хаты белән кызыксындырыла:

а) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан, милек рәвешләренә һәм кайсы ведомствога каравына карамастан, предприятиеләрнең һәм оешмаларның хезмәт коллективлары;

б) Россия Федерациясе гражданнары.

1.3. Рәхмәт хаты белән бүләкләүгә тәкъдимнамәне, милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, предприятие һәм оешма коллективлары, җәмәгать оешмалары, Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары кертә.

1.4. Бүләкләүгә тәкъдимнамә бүләкләү күздә тотылган көнгә кадәр 15 календарь көннән дә соңга калмыйча кушымта итеп бирелгән рәвеш буенча (кушымта) кертелә.

1.5. Рәхмәт хаты белән кызыксындыру турында карар Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгы (алга таба – район Башлыгы) яисә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе (алга таба – район Башкарма комитеты җитәкчесе) тарафыннан кабул ителә.

1.6. Рәхмәт хаты белән кызыксындыру район Башлыгы яки район Башкарма комитеты җитәкчесе карары нигезендә башкарыла.

1.7. Рәхмәт хаты белән кызыксындыру турында карар һәм Рәхмәт хаты тексты ике дәүләт теленең берсендә рәсмиләштерелә.

1.8. Рәхмәт хатын тапшыру тантаналы шартларда район Башлыгы яки район Башкарма комитеты җитәкчесе яисә аларның вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан башкарыла.

1.9. Рәхмәт хаты белән кызыксындыруга бәйле чараларны матди-техник һәм оештыру ягыннан тәэмин итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлеге гамәлгә ашыра.

1.10. Рәхмәт хаты белән кызыксындыру турындагы карар гаммәви мәгълүмат чараларында рәсми рәвештә басылып чыгарга яисә Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

## II. Рәхмәт хатының тасвирламасы

2.1. Рәхмәт хаты А4 форматындагы кәгазьдә башкарылган (180-240 гр).

2.2. Рамканың өске өлеше бизәкләп эшләнгән. Үзәктә район гербы сурәтләнгән һәм рус һәм татар телләрендә исеме язылган.

2.3. Бизәүнең өстәмә элементлары каралган – пыяла белән агач кысалар.

2.4. Рәхмәт хатына кертелә: бүләкләнүченең исеме һәм атасының исеме, хат тексты, район Башлыгының (аның вазыйфаларын башкаручы затның) яисә район Башкарма комитеты җитәкчесенең (аның вазыйфаларын башкаручы затның) имзасы.

**Татарстан Республикасы**
**Балык Бистәсе муниципаль районының**
**Рәхмәт хаты турындагы Нигезләмәгә**
**кушымта**

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районының
Рәхмәт хаты
белән кызыксындыруга

ТӘКЪДИМНАМӘ

Ф.И.А.и. (оешманың аталышы)________________________________________________

______________________________________________________________________

Туган елы, ае, числосы (төзелү датасы) ____________________________________

______________________________________________________________________

Белеме, уку йортының исеме (аталышы), тәмамлау елы

______________________________________________________________________

Эш урыны һәм вазыйфасы ______________________________________

Гомуми эш стажы _____________________________________________________

Тармактагы эш стажы ___________________________________________________

Әлеге предприятиедәге эш стажы ________________________________________

Дәүләт бүләкләре ______________________________________________________

Кызыксындыруларның, бүләкләүләрнең башка төрләре

________________________________________

Конкрет казанышлар күрсәтеп бүләкләүгә тәкъдим ителүчегә сыйфатлама

Кызыксындыруның инициаторы:

Җитәкче (җирле үзидарә,
оешма, предприятие, иҗтимагый оешма органы) ______________
(имза)

М.У. 20___ елның ____ ___________